Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган мәктәп туры олимпиада биремнәре.
2017-2018 уку елы. 6 нчы сыйныф.

(Максималь балл - 49)

Олимпиадные задания школьного тура по татарскому языку для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык).
2017-2018 учебный год. 6 класс

(Максимальное количество баллов - 49)

1. Прочитайте текст.

А) Озаглавьте. (2 б.)

Б) Допишите окончания. (По 0,5 б. = 2, 5 б.)

Менә ак тунлы кыш та килеп җитте. Бер-ике көн эчендә әллә никадәр кар яуды. Бөтен тирә-як ак юрган астында калган кебек.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр яса... һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәт... кушты. Без моңа шатланып риза булдык. Мәктәптән кайткач, һәрберебез җимлек ясый башладык.

Мин дә тактадан кечкенә өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман янындагы карт чыршы төбенә куйды... . Чыршының ботаклары җимлектәге азыкны кардан сакларлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли. Шуңа күрә урман янындагы өйдә яши... .

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, кипкән миләшләр салдым. Кунакларым көттермәде. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар да агач ботагына кундылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Алар миләш яраталар икән. Рәхәтләнеп миләш ашадылар. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән ашарга ашыкмыйлар әле. Кинәт җимлек өстендәге ботакка тиен сикереп менде. Ул да миләштән авыз ит.... Хәзер мин көн буе канатлы дусларыма җим бирәм. Тиеннәр дә рәхим итсеннәр. (*Ш.Бикколдан*)

2. Проверьте, как вы поняли текст, выполните тест. (За каждый правильный ответ 1 б. = 6 б.)

1) Снег шел ... .

а) целый день

б) несколько суток

в) в течении одного двух дней

2) Учительница нам велела смастерить кормушки, мы… .

а) не хотели этим заниматься

б) с удовольствием сделали кормушки

в) решили сделать потом

3) Кормушку поставил рядом … .

а) со школой

б) с домом

в) под старой елью

4) Наш дом находится … .

а) в деревне

б) около дороги

в) в лесу

5) Первыми прилетели в мою кормушку …

а) воробьи

б) синички

в) птички не прилетели, только белка полакомилась

6) Снегири, оказывается очень любят… .

а) хлеб

б) зерно

в) сушеную рябину

3. Найдите синонимы следующих слов. (За каждое слово 0,5 б. = 3 б.)

кечкенә -

әйбәт -

авыз итте -

азык -

якшәмбе -

канатлы дусларым -

4.Допишите предложения. (По 1 б. = 4 б.)

1). Кыш көне кошларга җимлекләр ясарга кирәк, чөнки ... .

2). Чыршының ботаклары җимлектәге азыкны кардан саклый, шуңа күрә ... .

3). Әтием урманчы булып эшләгәнлектән,өебез ... .

4). Кошлар ипи, ярма, кипкән миләшләр яратканга, мин ... .

5. От каких существительных образованы слова. (По 0,5 б. = 1,5 б.)

урманчы –

тунлы –

җимлек -

6**. Найди предложение с грамматической ошибкой.** (2 б.)

1) Тәрәзәдән сентябрь аеның җылы нурлары керә.

2) Кайбер кешеләр көзне яратмыйлар.

3) Кошлар көньякка очалар.

4) Көз тирә-юньдә алтын төскә буяды.

7. Раскройте скобки, ставьте в нужном падеже. (2 б.)

Мин (тәрәзә) урмандагы каенга карарга яратам.

Камил әтисе белән (урман) барды .

Тиен (тавыш) курыкты.

Мәктәп (бакчасы) матур чәчәкләр үсә.

8. Выберите к прилагательным подходящее по смыслу существительное. (За каждый пример 0,5 б. – до 3 примеров = 6 б.)

Яңгырлы ..., ...,

Тарихи ..., ...,

Бай ..., ...,

Кызыклы .., ...,

9. Допишите продолжение рассказа (8 -10 предложений). (За каждое предложение 2 б. = 20 баллов)

Урамнан кыз белән малай бара. Ә бераз алдарак бер әби бара. Юл бик тайгак. Әби таеп китә дә егыла.